**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Илбәк авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Илбәк авылы № 127 15 июня 2015 ел

«Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлегенең 2012 елның 17 октябрендәге 45 номерлы карары (22.02.2013 № 55 карары редакциясендә) белән расланган Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану һәм эш итү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында»

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 26.3 статьясына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 27 маендагы 136-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Илбәк авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. 1 бүлекнең 1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, «Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлегенең 2012 елның 17 октябрендәге 45 номерлы карары (22.02.2013 № 55 карары редакциясендә) белән расланган Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану һәм эш итү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«1.3. Муниципаль милектә түбәндәгеләр булырга мөмкин:

1) «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Азнакай муниципаль районының «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы белән билгеләнгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән мөлкәт;

2) җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт, федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очракларда, шулай ук җирле үзидарә органнарының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 06.10.2003г. 131-ФЗ номерлы Федераль

законның 15 статьясындагы 4 өлешендә каралган тәртиптә тапшырылган мөлкәт;

3) Илбәк авыл җирлеге Советының норматив хокукый актлары нигезендә җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәткәрләре эшчәнлеген тәэмин итү өчен билгеләнгән мөлкәт;

4) җирле үзидарә органнарына федераль законнар белән хәл итү хокукы бирелгән һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле мөлкәт;

5) “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 06.10.2014 № 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 4 өлеше нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән мөлкәт, шулай ук күрсәтелгән Федераль законның 17 статьясындагы 1 һәм 1 өлешләре нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт.”.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo. tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлегенең Законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча Илбәк Советының даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис М. З. Габделвәлиева